**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменения в статью 8 Закона Республики Татарстан «О регулировании отдельных вопросов в сфере социального обслуживания граждан в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
14 июля 2022 года

**Статья 1**

Внести в часть 8 статьи 8 Закона Республики Татарстан от 18 декабря 2014 года № 126-ЗРТ «О регулировании отдельных вопросов в сфере социального обслуживания граждан в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 12 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 1 (часть I), № 22 (часть I), № 54 (часть I); 2021, № 29 (часть I), № 93 (часть I) изменение, дополнив ее пунктом 7 следующего содержания:

«7) доставка организациями социального обслуживания, имеющими автотранспорт, приобретенный в рамках федерального проекта «Разработка и реализация программы системной поддержки и повышения качества жизни граждан старшего поколения «Старшее поколение» национального проекта «Демография»:

лиц старше 65 лет, проживающих в сельской местности, в медицинские организации;

лиц старше 65 лет и инвалидов, проживающих в сельской местности, в организации социального обслуживания, предоставляющие социальные услуги в полустационарной форме социального обслуживания.».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.
2. Пункт 7 части 8 статьи 8 Закона Республики Татарстан от 18 декабря 2014 года № 126-ЗРТ «О регулировании отдельных вопросов в сфере социального

обслуживания граждан в Республике Татарстан» действует до 31 декабря 2024 года включительно.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
25 июля 2022 года
№ 46-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 14 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«7) «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын арттыру программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру» федераль проекты кысаларында сатып алынган автомобиль транспорты булган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан түбәндәгеләрне китерү:

авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны медицина оешмаларына;

авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны һәм инвалидларны социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге

126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешенең 7 пункты 2024 елның 31 декабренә кадәр (шул көнне кертеп) гамәлдә була.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 25 июль
№ 46-ТРЗ